# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Красная Горка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**22 ноябрь 2023 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Красная Горка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Юл - урам челтәрен тигезләү өчен машина юлларына вак таш сатып алу»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 12 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 8 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 6 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә Красная Горка авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Красная Горка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада

укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Юл - урам челтәрен тигезләү өчен машина юлларына вак таш сатып алу»

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә , халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Красная Горка авылы, Бакча урамы, 8 йорт адресы буенча, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары И.Н. Габдрахманов